# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**13 ноябрь 2020 ел** **№1**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Уставы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары (җыен) нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру); Сәпәй авылы зиратлары;
- Сәпәй авылы урамнарына юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәпәй авылында энергия саклаучы урам яктырткычлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
-җәйге чорда Сәпәй авылында территорияне чабу (ягулык, триммер өчен запас частьлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәпәй авылында юлларны грейдерлау, кардан чистарту (ягулык сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Сәпәй авылы территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәпәй авылында бәйрәм чаралары үткәрү (бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Халыкара өлкәннәр көне”, “Яңа ел” бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия 498 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенында катнашып тавыш биргән гражданнар саны 355.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«РИЗА» позициясе өчен 355, «КАРШЫ» » позициясе өчен 0 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәнәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип танырга:

«Сез, 2021 елда 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм анда катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, түләүне бер тапкыр киметеп 2 төркем инвалидлар өчен 175 сум күләмендә Азнакай муниципаль районы Сәпәй авыл җирлеге Сәпәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тоту белән ризамы:

- Контейнер мәйданчыклары урнаштыру (киртәләр алу өчен материаллар сатып алу, коймалар ясау һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары урнаштыру (нигез, киртәләр урнаштыру); Сәпәй авылы зиратлары;
- Сәпәй авылы урамнарына юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәпәй авылында энергия саклаучы урам яктырткычлары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү;
-җәйге чорда Сәпәй авылында территорияне чабу (ягулык, триммер өчен запас частьлар сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәпәй авылында юлларны грейдерлау, кардан чистарту (ягулык сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү;
- Сәпәй авылы территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Сәпәй авылында бәйрәм чаралары үткәрү (бүләк, сувенир продукциясе сатып алу, “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Халыкара өлкәннәр көне”, “Яңа ел” бәйрәм чараларын үткәрү буенча хезмәт күрсәтү).

3. Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Сәпәй авыл җирлеге мәгълүмати стендларында һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakayevo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Сәпәй авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Сәпәй авыл җирлеге башлыгы Ф.Г.Галиева